ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘҖМӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

09.06.2020ел №11

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләү гәфакттагы чыгымнар турында квартал саен белешмәләр бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, муниципаль Әҗмәр авылҗирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әҗмәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны турында квартал саен белешмәләрне һәм аларның хезмәте өчен түләү гәфакттагы чыгымнарны бастырып чыгару тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Әҗмәр авыл җирлегебашлыгы Р.М.Вәлитов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
2020 елның 9 июненнән № 11

Әҗмәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен белешмәләр бастырып чыгару тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әҗмәр авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен бирелә торган белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе (алга таба - Тәртип) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Әҗмәр авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Тәртип Әҗмәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә фактик чыгымнар турында квартал саен бирелә торган мәгълүматларны (алга таба - белешмәләр) тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели.

## II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында белешмәләрне тапшыру һәм аларның составы

2.1. Белешмәләр квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача исемлек саны турында, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Әҗмәр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына карата түләүләрне исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын гамәлгә ашыруга фактта җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен (акчалата тотуны) чагылдыра.

2.2. Белешмәләр хисап чорыннан соң килә торган айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге рәвеш буенча тапшырыла.

2.3 Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

## III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе

3.1. Әҗмәр авыл җирлегенең башкарма комитеты хисап чорыннан соң килүче айның соңгы санынннан да соңга калмыйча Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитетының белешмәләрне раслау турындагы карары проектын әзерли.

3.2 Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр хисаптан соң килүче икенче айның соңгы санына кадәр Әҗмәр авыл җирлеге сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләре
саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы
чыгымнар турында квартал саен бирелә торган
белешмәләрне бастырып чыгару тәртибенә кушымта

Әҗмәр авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең саны һәм аларның хезмәте өчен хисап чорының________________2020 елгы түләүгә факттагы чыгымнар турындагы белешмәләр (беренче квартал, яртыеллык, тугыз ай, бер ел)

| Хезмәткәрләркатегориясе | Хисапчорындахезмәткәрләрнеңуртачаисемлек саны, кеше | Хисапчорындахезмәткәрләргәхезмәтөчентүләүгәфакттагычыгымнар, меңсум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Спас муниципальрайонының Әҗмәр авылҗирлегемуниципальберәмлегененҗирлеүзидарәорганнарыхезмәткәрләре | | |
| шулисәптән: муниципальхезмәткәрләр | | |